**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№03**
**11.01.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Шәһәр мунчалары» МКП мөрәҗәгатен караганнан соң, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 1 февралендәге 511 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 11 гыйнварындагы
03 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Шәһәр мунчалары» МКП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

<table>
<tr><th>№ т/б</th><th>Халык категориясе</th><th>1 кешегә хезмәттән файдалану дәвамлылыгы</th><th>Тариф күләме, сум (өстәмә кыйммәткә салымнан тыш)</th></tr>
<tr><td>1.</td><td>Мунчаларның гомуми бүлегендә юыну хезмәтләре:</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>-</td><td>Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, фашист концлагерьларының балигъ булмаган тоткыннары, «Блокадаланган Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, Социалистик хезмәт Геройлары, СССР Геройлары</td><td rowspan="8">1 сәгать 45 минут</td><td rowspan="4">түләүсез</td></tr>
<tr><td>-</td><td>Бөек Ватан сугышы инвалидлары</td></tr>
<tr><td>-</td><td>диализда торучы, сәламәтлекләре буенча инвалидлар</td></tr>
<tr><td>-</td><td>7 яшькә кадәрге балалар</td></tr>
<tr><td>-</td><td>1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорын кертмичә) яисә Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар</td><td rowspan="2">100,00</td></tr>
<tr><td>-</td><td>һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннары</td></tr>
<tr><td>-</td><td>барлык категория пенсионерлар</td><td>170,00</td></tr>
<tr><td>-</td><td>гражданнарның башка категорияләре</td><td>230,00</td></tr>
<tr><td>2.</td><td>Бассейннан файдалану хезмәтләре:</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>-</td><td>гражданнарның барлык категорияләре өчен</td><td rowspan="2">45 минут</td><td>120,00</td></tr>
<tr><td>-</td><td>барлык категория пенсионерлар</td><td>90,00</td></tr>
</table>

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева